ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БЕТЬКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422649, с. Бетьки,
ул. Мира, дом 11

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БӘТКЕ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422649, Бәтке авылы,
Тынычлык урамы, 11 нче йорт

Тел.: (84361) 26235, факс: (84361) 26235, e-mail:bet.rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.r

# КАРАР № 8

Бәтке ав. 2016 елның 1 апреле

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе
муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге
территориясен төзекләндерү буенча
санитар чистарту икеайлыгы үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 19 пункты (07.12.2011 ел редакциясендә), Бәтке авыл җирлеге администрациясе 12.04.2012 ел, № 6-п «Бәтке авыл җирлеге территориясендә территорияләрне санитар тоту, җыештыру, чисталык һәм тәртипне тәэмин итү кагыйдәләрен раслау турында» карары нигезендә карар бирәм:

1.2016 елның 1 апреленнән 1 июненә кадәр Бәтке авыл җирлеге территориясен санитар чистарту һәм төзекләндерү айлыгы игълан ителде.
2. Бәтке авыл җирлеге территориясен санитар чистарту буенча чаралар үткәрүнең барышын тикшерү өчен комиссия төзү (2 нче кушымта)
3. Җирлек территориясен санитар чистарту һәм төзекләндерү буенча икеайлык чаралары планын расларга (2 нче кушымта).
4. Бәтке авыл җирлеге территориясендә урнашкан барлык милек формасындагы предприятие, учреждение җитәкчеләренә һәм шәхси эшмәкәрләргә:
4.1. Аларга беркетелгән территорияләрне (беркетелгән территорияләр «Бәтке авыл җирлеге «муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү турында " нигезләмәдә билгеләнгән.
4.2. Төзелеш һәм көнкүреш чүп-чары санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү.
5. Бәтке авыл җирлеге территориясен санитар чистарту һәм төзекләндерү айлыгы турында игъланнар аша халыкка хәбәр итү.

6.Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Бәтке авылы,Ленин урамы,4 йорт; Яншык авылы, Җиңүнең 40 еллыгы урамы, 23 йорт; Кече Укмас авылы, Гагарин урамы, 9Б йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

7.Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Бәтке авыл җирлеге Башлыгы Ф.М.Динмөхәммәтов